**СОВЕТ ПЕЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422612 с. Пелево,
ул. Советская , д. 9
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПӘРӘҮ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422612 Пәрәү авылы,
Совет урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

**2025 елның 30 апреле** **11 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 13 апрелендәге 40 номерлы Пәрәү авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләре рәисләренең, рәис урынбасарларының, контроль-хисап органнары аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 10 апрелендәге 5 номерлы Пәрәү авыл җирлеге Советы карарына (10.05.2018 №42, 19.10.2018 №53,14.08.2020 №25, 28.10.2022 №23-1,23.01.2023 №3-1, 28.06.2024 №17, 18.11.2024 №349 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге Советы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта «13 990» саннарын «15 389» саннары белән алыштырырга;

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларында күрсәтелгән карар белән расланган:
4 пунктта «12,86» саннарын «15,48» саннары белән алыштырырга;

7 пунктның 5 пунктчасында «41 процент «сүзен» 58 процент «сүзләре белән алыштырырга;
«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең Хезмәткә түләү фондын формалаштыру» 2 пунктының 6 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләре белән алыштырырга;
күрсәтелгән карарның 1 нче кушымтасын яңа редакциядә (кушымта) бәян итәргә. Күрсәтелгән карарның 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (кушымта)бәян итәргә.

1. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль районның Пәрәү авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Пәрәү**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Ф.Ф. Тимергалиев**

Татарстан Республикасы муниципаль районының
Пәрәү авыл җирлеге Советының 2018 елның
13 апрелендәге 40номерлы карарына 1нче кушымта
*(ТатарстанРеспубликасы муниципаль районының 2025 елның 30 апрелендәге 11 номерлы Пәрәү авыл җирлеге Советы карары редакциясендә)*

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл җирлекләрендә һәм шәһәр торак пунктларында | | | |
| | Тугызынчы төркем <*> | Унынчы төркем <*> | Унберенче төркем <*> | Уникенче төркем <*> |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 28 632 | 25 091 | 23 091 | 21 091 |

<*> Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлек кергән хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләмен билгеләү максатыннан тиешле муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына карап түбәндәге хезмәт хакы төркемнәре буенча бүленә:

1) шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә барлыкка килгән авыл һәм шәһәр торак пунктлары:
тугызынчы төркем 10 меңнән артык кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;
унынчы төркем - халык саны 5 меңнән 10 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;
унберенче төркем - 1,5 меңнән 5 меңгә кадәр кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;
уникенче - төркем халык саны 1,5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Пәрәү**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Ф.Ф. Тимергалиев**